ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 май 2026ел № 4549

Башкарма комитетның 2026 елның 22 гыйнварындагы 468 номерлы Карары белән расланган «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2026 елның 22 гыйнварындагы 468 номерлы Карары белән расланган «2026-2028 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлектә «УЮЧның норматив техник халәтен ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту» графасында «Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү (муниципаль программага кушымта)» сүзләрен «Юл-транспорт һәлакәте концентрациясе урыннарын бетерү» сүзләренә алмаштырырга;

2) муниципаль программага кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов